# КӨТЕЛГӘН БИКӘЧ

Вәли мәхдүмнең кечкенә малай вакытында, әтисе кунактан кайтып:

— Угылым, синен бәхеткә Габдерахман хәзрәтнең авыру кызының колагыны тешләдем. Бәхетле икәнсең, терелде! — дигән сүзенә ул әллә никадәр хурланды. Аягын тибеп-тибеп:

— Мин өйләнмим! Мин шәкерт булам! Мин зур мулла булам! — дип кычкырып еглады. Туталарының мыскыл итеп:

— Габдерахман мулла кияве! — дигән сүзенә дә хурлана-хурлана алар берлә талашты, сугышты; битләрен тырнады, чәчләрен йолкыды. Кунакка килгән мулланың бундан зур малае да моны:

— Кияү-мияү! — дип мыскыл итүенә чыдый алмаенча, аның яңа кәләпүшене пычракка ыргытты; аның битенә туфрак та сипте. Су коенып кайтканда оршышып киткән күрше малайлары берлә дә шуның хакында әллә ничә сугышты. Үзләренә килгән кунак хатыннарының:

— Менә сиңа Лулуны алып бирәләр инде! — дигән сүзеннән хурланып, чәй яныннан торып та китте. Әнисе берлә ашка барган йирендә шуны сөйли башлагач, ул акырып еглап чыгып та китте. Ләкин һичберсе аны «Лулу кияве» дип үртәүдән туктамады; һичбер урам малае «кияү-мияү» дип мыскыл итүдән айнытмады. Ул кай көннәрне көн буе әллә ничә йирдә аның тәмле уенын шул «кияү» дигән сүз берлә бозганга, аның шул матур кәефен шул сүз — оят сүз берлә йибәргәнгә, төннәрене үзе белгән догаларны укып, шул кызның үлүен теләде. Шул Габдерахман мулланың бетүен, исеменең онытылуын, шул малайлар, хатыннар, зур кешеләрнең үртәүләре бетүен Алладан сорады. Күз яшьләре берлә шул теләүнең хаклыгын ныгайтты.

Ләкин дога кабул булмады. Сөйләүчеләр һаман сөйләде, үртәүчеләр һаман үртәде. Вәли мәхдүм шул оят «кияү» дигән сүздән газап чиккәннән чикте. Аның бәхетсезлегенә каршы, тагы йитмәсә менә, Габдерахман хәзрәт тә килде. Әллә никадәр муллалар арасында, чәй эчкәндә, Вәли мәхдүм кайнар коймакны күтәреп чыгарганда, Вәли мәхдүмгә карап:

— Мулла Нигъмәтулла, минем кызны шул угылыңа колагын тешләдеңме? Шәп егет икән. Кил әле, мәхдүм, тәңкә бирим әле! -диде.

Ул шул сүз берлә Вәли мәхдүмнең ябылып килә торган ярасын тагы уятты. Вәли мәхдүм, тәңкәне алу кайда — тәрилкәне куяр-куймас, кып-кызыл ахак кеби булып чабып чыкты. Беркемгә дә күренмәенчә, печәнлеккә менеп ятып, печәнлекнең түбә ярыкларыннан керә торган кояш нурын карап-карап, үзенең шул бәхетсезлеген уйларга тотынды. Үзен шулкадәр мыскыл иттерүче этисенә үч итәр өчен, үзен шулкадәр үртәүче апаларына күз яше агыздырыр өчен, ул үләргә уйлады. Ул үзен үлгән иттереп күрә башлады. Менә этисенең, әнисенең, апаларының еглавын күргән кеби булды. Ул аларның шул җинаятьләре өчен җәза күрүләренә шатланып көлеп тә китте. Алладан тагы үлүен, бүген үк, хәзер үк үлүен теләргә тотынды. Алла тагы догасын кабул итмәде. Үртәүчеләр һаман туктамады.

Вәли мәхдүм үсте. Ул хәзер сарыф та укырга тотынды. Ләкин аның берлә бергә, аннан калмаенча, моның кияүлеге, моны шул сүз берлә үртәү дә үсте. Аны инде өйдә, урамда гына түгел, мәдрәсәдә шул сүз берлә кызарта башладылар. Малайлар гына түгел, зур шәкертләр дә:

— Лулу кияве! — дип, үрти башладылар.

Ул Габдерахман хәзрәткә, Лулуга, үзенең шул язмышына кырык мәртәбә ләгънәтләр укыды, кырык мәртәбә этиләреннән үч алырга вәгъдәләр кылды. Ләкин көн үтте, көн үткән саен Вәли мәхдүм үсте; ул үскән саен теге уй аны ташламады.

Менә дәрес «Шәрхе мулла»га да йитте. Ул шул көлүләргә, үртәүләргә бигүк әһәмият бирми башлады. Ул хәзер, элгәреге кеби, «кияү-мияү» дигән тавыштан куркынып качмый башлады.

Менә беркөнне аны мәхдүм итеп кияү берлә кыз янына иртәнге чәйгә чакырдылар. Шул чакыру аңар тагы үзенең теге Лулу вакыйгасыны исенә төшереп, кәефене йибәрсә дә, ул ашка китте. Аны, аның берлә тагы берничә бай малаен зур, һәйбәт кияү өенә керттеләр. Исле май исе берлә тулган, күбрәк тәрәзәләре капланып, ярты караңгы ясалган бүлмәләр, әллә нинди сер саклар

өчен ясалган кеби тора торган калын пәрдәләр, акыртын гына качып йөргәндә аяк тавышыны ишеттермәс өчен, бөтен тавыш-тынны үзенә генә сеңдерергә кеби җәелгән паласлар әллә нинди үзенә бер төрле тәэсир итте; Вәли мәхдүмнең сеңерләрене киерми, аны әллә нинди курку берлә шатлану арасында бер хиснең баскычына бастырды. Пөхтә киенгән үз мәхәлләләренең бай угылы кияүне күрү аны каушатты. Зифа гына буйлы, нечкә генә билле, көләмчән йөзле бикәчне күрү аны кызартты. Ул, кып-кызыл булып, урынына утырып, ясаган чәйне эчәргә тотынды. Әллә никадәр кәнфитләр, чәкчәкләр, башка ашлар берлә тулган өстәл дә аның дикъкатен җәлеп итә алмады. Ул, башын күтәрмәенчә, алдындагы чикләвекне ашарга, ясаган чәйне чөмерергә тотынды. Кияү:

— Мәхдүм, аша! — дисә дә, ул кәефен боза алмады. Теге малайлар да күп сөйли алмаганга, барысы да әллә нинди зур бер оят эш эшләгән кеби, әллә нинди бер хис астында изелделәр, бөтен мәҗлеснең тәме булмады. Кияү, шул кәефсезлекне таратыр өчен кеби:

— Менә сезгә машина уйнатыйм әле,—дип торып китеп, озак кына борып уйната башлады.

Вәли, машинаны карар өчен, башын күтәрде. Аның күзе машинадан элек, чәй ясап маташа торган бикәчкә төште. Ул аның озын керфекләренең күзен нурландырып торуын, битенең уртасының аз гына эчкә таба уелып керүен, калфак астында чем-кара саченең кара урмандагы җансыз күл кеби томрап торуын карарга тотынды. Аның колагы музыка тавышын ишетсә дә, күзе шул бикәчтән алынмады. Ул бикәч аңар бик матур, бик зифа, бик пөхтә тоелды, ул оҗмахтагы хур кызы кеби, аннан да матур кеби күренде. Аның күңеленә келт итеп Лулу төште. Беренче мәртәбә ул шул фикер килгәндә оялмады, кызармады.

Аның уе Лулуга күчте. Ул да шул бикәч кеби матур, шул бикәч кеби пөхтә, шул бикәч кеби нәзек булып, күз алдына килеп басты. Вәли мәхдүм:

— Ул минеке, ул, шулкадәр матур Лулу минеке! Ул бервакыт менә шул кыз кеби минем бикәчем булачак! — диде. Шул уй бу юлы аңар, оят тоелу

кайда, хәтта кәефле кеби дә булды. Шул уй аны көн буе ташламады. Кич берлә ул Лулуны төшендә дә күрде. Ул әллә нинди нечкә генә пәрдә берлә капланган кеби томан астында төсле тоелса да, аның озын керфекләреннән нур чәчелгәне күренгән кеби булды. Ул шул төшкә шатланып уянды, шул томанлырак Лулуның сыны аның күз алдыннан китмәде. Габдерахман хәзрәт тә аңар якынрак кеби күренә башлады. Ул шул Лулуны уйлап, шул Лулуны бикәче иттереп уйларга тотынды. Аннан соң аны хатын иттереп, аннан соң Лулуны остазбикәсе иттереп тә уйлады. Аның күңелендә, әллә нинди, Лулуны күрәсе килү уе туды. Ул шул аны күрү уе берлә авырды. Ахырдан, уйлап-уйлап, Лулуның моннан дүрт йөз чакрымдагы бер шәһәрнең хәзрәтенең кызы икәнлеген хәтерләп, анда барып булмаулары, фәләннәре — һәммәсе күз алдына килеп басып, аны бераз тындырды.

Ул, Лулуга хуҗа булыр өчен, шул оҗмах хурыннан да матур Лулуга кияү булып керер өчен тырышып укып мулла булырга кирәк икәненә төшенеп, укырга тотынды. Лулуга кияү булыр өчен тырышырга башлады.

Лулу уе аны ташламаса да, ул мәдрәсәне тәмам итте.

Шул сәгадәтле көн йитә дигәндә, шул, керфекләреннән нур чәчә торган томанлы Лулуны кочакларга, үбәргә, сөяргә сәгатьләр йитә дигәндә, этисе Коръән хафиз кылырга кушты. Ул, Лулу өчен Коръән хафиз кылырга да тотынды. Тырышты, тырмашты, Коръәнне ядка алып бетерде.

Шунларның һәммәсен дә Лулу өчен эшләгәнгә, беткәч тә әллә никадәр кәефләнде. Төшендә Лулуны тагы матуррак күреп, тагы теге матур көнне көтәргә тотынды. Ләкин эш тагы кичекте: этисе «Тәфсир», «Хәдис» укыр өчен Гарәбстанга йибәрергә булды. Лулуның сәгадәте өчен, Лулу ире Коръән хафизга башка «Тәфсир», «Хәдис» тә укыган булуы өчен, ул Гарәбстанга китәргә разый булды.

Одессада чем-кара саче биленә йиткән бер еврей кызын күргәч тә ул Лулуның сачен күргән кеби булды. Шул көнне төнге төшендә ул теге томанлы Лулуны теге еврей кызыныкыннан да зур, куе, матур сачле иттереп күрде.

Парахутта барганда бөтен парахутны үзенең зифа буе берлә исен китерә торган грузин кызын күргәч тә ул Лулуны исенә төшерде. Аңар Лулу шул грузин кызыннан да зифа, аның сыны да шул грузин кызыннан матур кеби тоелды. Төшендә күргәндә, дөресте дә, ул теге томанлы Лулуны, нурлы керфек, озын кара сачкә башка, грузин кызыннан да зифа, матур иттереп тапты.

Ул Истанбулда йөргәндә күзеннән күңеле күренеп тора торган, күзе берлә бөтен дөньяны сөя торган кеби карый торган төрек кызын күрде. Аның хәтеренә Лулу килеп төште. Аның күзе, теге озын, нур чәчә торган керфек берлә, шул төрек кызының мәгънәле, сөйкемле күзеннән дә сөйкемлерәк кеби тоелды. Аннан да мәгънәлерәк кеби күренде. Тагы күргән төшендә ул теге Лулуны матур керфек астыннан бер каравы берлә патшаларны кол итә торган күзле иттереп күрде.

Каһирәдә урамда йөргәндә ул кобыт кызларының, юри ясап куйган кеби, югарыга таба карап тора торган күкрәкләрен күрүе дә аңар Лулуны уйлатты. Аңар Лулуның күкрәге дә шул кобыт кызының бөтен дөньяның ирләрене алдар өчен табигатьнең юри биргән имчәкләреннән дә шәп кеби күренде. Ул тагы күргән төшендә, дөресте дә, аны шул югары таба карап торган күкрәк берлә зиннәтләнгән итеп тапты.

Ул француз театрында күршесенә утырган бер француз кызының, бөтен тирә-яндагыларны хәйрәткә калдыра торган йөзенең матурлыгына гаҗәпкә калганда да Лулуны уйлады. Аның Лулусының йөзе — шул француз кызының йөзеннән матур, аның Лулусының йөзе бөтен дөньяга кайгысын оныттырыр кадәр гүзәл кеби тоелды. Төшендә күргәндә, дөресте дә, Лулуның йөзе матурлыгы берлә бөтен дөньяны көлдерерлек икәненә ышандырды.

Ул Мәккә берлә Мәдинә арасында кәрван берлә барган чакта, бер мәнзилдә, гарәп кызының энҗедән ак тешләрен күреп хәйранга калды. Тагы Лулуны исенә төшерде. Ул Лулуның да тешләре шул матурлыгы берлә бөтен ямьсез сахраны матурландыра торган, матурлыгы берлә шул җансыз ком

диңгезенә җан бирә торган гарәп кызының тешеннән дә матур кеби иттереп уйлады. Дөя өстендә күргән төш шул фикернең дөрестлеген белгертте...

Коръән, хәдис дәресе тәмам булды. Вәли мәхдүмгә кайтырга рөхсәт килде. Ул үзенең Лулусының сәгадәте өчен шул Гарәбстандагы мәшәкатьләрне дә онытты. Ул, шул сәгадәткә тизрәк, тизрәк дигән кеби, Россиягә таба юнәлде. Юл буе Лулу фикере аны ташламады. Бик аз төн ул Лулуны төшендә күрмәенчә калды.

Өйгә кайтып йитте. Лулу өчен, аның сәгадәте өчен, башына Коръән, тәфсир, хәдис, әллә никадәр фикъһе, ысул мәсьәләләре тутырып, этисе янына имамлыкка тамга да алды. Шул Лулу өчен, яше егерме йидедә булса да гыйффәтен дә саклаганга, яучы китү берлә туйны көтә башлады.

Көн үтте, сәгадәтле минутлар якынлашты — кыз вәгъдәләшелде. Туйга кителде. Монда никях та укылды, Вәли мәхдүмне алырга атлар да килде. Дүрт йөз чакрымлы ат сәфәре дә Лулудыр дию берлә тоелмаенча үтте. Сәгадәтле минут якынлашты — шәһәр күренде... Вәлинең күзе алдына: озын сачле, зифа буйлы, матур йөзле, энҗе тешле, зур күләр күзле, нурлы керфекле Лулу килеп басты. Ул аны көтә, аны шул, үзенең шулкадәр мәшәкатьләнеп укуы өчен, шулкадәр зур фидаилык кылып гыйффәтен саклавы өчен, шул матур саче берлә чолгап алырга, шул матур күз берлә көлеп карарга, шул матур ирен берлә үбәргә, шул зифа буе берлә кочагына керергә көтә кеби булды...

— Тыр-р!..

Вәли сикереп төшеп, әлеге уйдан аерыла алмаенча, ишеккә таба борылды. Ишекне ачу берлә ул, аны «әүлиям» дип көтеп тора торган Лулуның аягына егылмакчы, аның нечкә кулларын кысмакчы, аның ут кеби кызу авызын үпмәкче булды.

Ишек ачылды, ишек ябылды, чаршау селкенде. Вәли: «Лулу!» — дип әйтергә өлгермәде. Күз алдына: зур табак битле, калын куе кашлы, кечкенә күзле, утын кеби зур куллы, чүмәлә кеби зур тәнле бер хатын кулын сузды.

Вәлинең күз алды караңгыланды... Аның теге хыял кызы моның янына килеп басты. Ул, Вәлигә карап:

— Менә шуның өчен Коръән хафиз кылдың, шуның өчен мәдрәсәдә изелдең, шуның өчен Гарәбстанда өч ел тордың, шуның өчен, әллә ничә мәртәбә тугры килгәндә файдалана алмаенча, гыйффәтеңне сакладың! — диде.

Вәли, ни дигәнен белмәенчә, әллә нинди, бөтен дөньяны куркытырлык тавыш берлә:

— Лулу!! — дип кычкырды да егылды. Аның йөрәге ярылды.

Икенче көнне шәһәрнең бөтен мәсҗедләрендә Вәли хафиз рухына тәһлил намазы укылды.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Коръән хафиз кылу* — Коръәнны ятлау

*Хәйрәткә калу* — хәйран булу, гаҗәпләнү,искитү.

*Мәнзил* —төшә торган урын, туктап китә торган урын, станция

**Көтелгән бикәч** — Хикәя беренче тапкыр Г.Исхакыйның «Фамилия сәгадәте» (1912) исемле җыентыгына кертелгән.

Әсәр «Зиндан» җыентыгында басылды.

Текст 1912 елгы басмадан алынды.

*«Шәрхе мулла»* — мәдрәсәләрдә гарәп грамматикасын тәмамлаганнан соң укыла торган китап.

*Тәфсир* — Коръәнгә аңлатмалар.

*Кобыт* — Христиан динендәге Мисыр гарәпләре (коптлар).

*Фидаи* — үз-үзен аямаучы.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.137-142.